КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 5 декабрь г.Казань № 1102

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус һәм сөт продуктлары белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2018 ел, 4 сентябрь, 752 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус һәм сөт продуктлары белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2018 ел, 4 сентябрь, 752 нче карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус һәм сөт продуктлары белән тәэмин итү буенча дәүләт эшенең күләмен яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 4 сентябрь, 752 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 5 декабрь, 1102 нче
карары редакциясендә)

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус һәм сөт продуктлары белән тәэмин итү буенча дәүләт эшенең күләме

| Балалар тукلануы өчен махсус сөт продуктлары алучылар категориясе | Возраст детей | Бер елга дәүләт эше күләме, бала-көн | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | адаптацияләнгән сыек сөт катнашмасы | сөт | кефир | эремчек |
| Җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнә торган яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган гаиләләрдә яшәүче өч яшькә кадәрге балалар; туклану өчен махсус һәм сөт продуктлары белән түләүсез тәэмин итү рәвешендә социаль ярдәм чарасы күрсәтелә торган авырулар исемлегенә керүче авырулары булган өч яшькә кадәрге балалар | 0 айдан 6 айга кадәр | 628 165 | - | - | - |
| | 6 айдан 1 яшькә кадәр | 2 487 475 | 2 487 475 | 2 487 475 | 2 487 475 |
| | 1 яшьтән 3 яшькә кадәр | - | 10 710 925 | 10 710 925 | 10 710 925 |
| ВИЧ-инфекцияле авыру аналардан туган балалар һәм ВИЧ-инфекция белән авыручы балалар | 0 айдан 6 айга кадәр | 18 980 | - | - | - |

____________________________________